**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА БАЛТАЙ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2018 елның 25 апреле № 83

**“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авылы җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаи зат буларак, җирле үзидарә органнарына сайланган, үз вәкаләтләрен даими гамәлгә ашыручы депутатларның хезмәте өчен түләү турында” 2018 елның 5 апреленда кабул ителгән 79 номерлы карарына үзгәртүләр кертү турында”**

2018 елның 24 апреленда чыккан 281 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карарына таянып, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авылы җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. 2018 елның 5 апреленда кабул ителгән 79 номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авылы җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаи зат буларак, җирле үзидарә органнарына сайланган, үз вәкаләтләрен даими гамәлгә ашыручы депутатларның хезмәте өчен түләү турында” Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авылы җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәртүләр кертергә:

1.1. 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7.Авыл җирлеге башлыгының хезмәт хакы күләме өлешендә айлык акчалата бүләк өчен түләү ел буе 4,65 акчалата бүләкләү күләменнән артмаска тиеш”

1.2. 2018 елның 5 апреленда 79 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авылы җирлеге карары белән кабул ителгән №2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга..

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Урта Балтай авылы җирлеге башлыгы Р.К. Хабибуллин**

05.04.2018 елда чыккан №79
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Урта Балтай авылы җирлеге Советы карарына
кушымта №2
(25.04.2018 елда чыккан №83
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Урта Балтай авылы җирлеге Советы карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авылы җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләме**

| Вазифа исеме | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 15 300 |